**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ КУТЕМИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул. Клубная, д. 1а, с. Кутема,
Черемшанский район, 423112

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**КУТӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Клуб урамы, 1- нче «а» йорт, Кутәмә
авылы,
Чирмешән районы, 423112

тел./факс +8(84396) 4-30-88
email:Kut.Cmn2@tatar.ru

**20.10. 2020** **№8**

# Татарстан Республикасы
# Чирмешән муниципаль районы
# Күтәмә авыл җирлеге Советы
# КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының 2018 елның 25 апрелендәге 83 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең айлык акчалата түләүләре һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында» карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының 2018 елның 25 апрелендәге 83 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, үз

вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карарының 1 өлешендәге 3 абзацын бәян итәргә:

1.1. «Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи окладының күләме 11 498 сум тәшкил итә»;

1.2. «2нче кушымтаны «Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата түләү күләме» яңа редакциядә бәян итәргә, кушымта нигезендә.

3. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

ТР Чирмешән муниципаль районы
Күтәмә авыл җирлеге
Башлыгы, Совет Рәисе А.М. Мордвинов

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Күтәмә авыл җирлеге
Советының 2020 елның 20
октябрендәге 8 номерлы
карарына 2 нче кушымта

Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен
даими нигездә гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгының
айлык акчалата түләү күләме

| Вазыйфаларның атамалары | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башлык | 15759,00 |